СОВЕТ КРАСНОГОРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Мира, д.11А, п.с-за “Мамадышский”,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422165

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КЫЗЫЛ ТАУ АВЫЛЫ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Мира ур., 11А нче йорт, “Мамадыш” совхозы поселогы, Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422165

тел.(факс): (85563) 3-91-14; e-mail: KrGor.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Решение — Карар

24 сентябрь 2018ел — № 2-36

**Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кызыл Тау авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм аларны куллану буенча җирле референдум үткәрү көнен билгеләү турында**

«Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 ел, 12 июнь, 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясының 2 пункты, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 ел, 6 октябрь, 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, "Жирле референдум турында» 2004 ел, 23 март, 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Кызыл Тау авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 11 статьясы, Кызыл Тау авыл җирлеге башкарма комитетының “Референдум уздыру инициативасы турында” 2018 нче елның 17 че сентябрендә кабул ителгән 40 номерлы карары, Кызыл Тау авыл җирлеге Советының “Референдум уздыру инициативасы турында” 2018 нче елның 17 че сентябрендә кабул ителгән 6-35 номерлы карары, Кызыл Тау авыл җирлеге Советының “Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Кызыл Тау авыл җирлегендә гражданнардан узара салым акчасын җыю һәм куллану кагыйдәләре” 2015 нче елның 9 че гыйнварендә кабул ителгән 3-19 номерлы (2018 №5-35 редакцисеяләрендә) карары нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кызыл Тау авыл җирлеге Советы К А Р А Р КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кызыл Тау авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм аларны куллану буенча җирле референдум үткәрү көнен 2018 нче елның 18 нче ноябренә билгеләргә.
2. Җирле референдумга чыгарыла торган мәсьәләне расларга:
"Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кызыл Тау авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 2019 елда 400 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм ул акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:

1. **Җирле әһәмиятле автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеген гамәлгә ашыру:**

-авылларда юллар төзекләндерү: “Мамадыш” совхозы поселогы - Банк урамы, Тукай тыкрыгы, Красная Горка авылы - Котып урамы, Керәшен Пакшины авылы - Тынычлык урамы, “Мамадыш” совхозының 2 нче фермасы поселогы - Гагарин урамы.

-Красная Горка авылында җәяүлеләр өчен салынган күперләрне төзекләндерү;

-Максим Пүчинкәсе авылы, Ташлы авылы, “Мамадыш” совхозының 2 нче фермасы поселогындагы күперләрне төзекләндерү;

- авыл җирлегенә караучы юлларны тигезләү һәм кардан чистарту.

2. **Җирлек территорияләрен төзекләндерүне оештыру:**

- урамнарны яктырту объектларына хезмәт күрсәтү (урам яктырткычларын төзек хәлдә тоту, сатып алу һәм яңага алыштыру).

3. **Җирлек халкының бергә җыелып ял итүе өчен шартлар тудыру**:

- Красная Горка авылында һәм “Мамадыш” совхозының 2 нче фермасы поселогында балалар мәйданчыклары урнаштыру;

4. **Җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне оештыру**:

- Максим Пүчинкәсе авылына су үткәрү.

« ӘЙЕ » « ЮК »

2. Әлеге карарны муниципаль берәмлек Советының мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен Мамадыш муниципаль районы Кызыл Тау авыл җирлеге башлыгы В.А.Гиззатуллина йөкләргә.

Мамадыш муниципаль районы
Кызыл Тау авыл җирлеге башлыгы,
Совет председателе /Гиззатуллина В.А./

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ «КРАСНОГОРСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ» МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА ИНН 1626001027
СОВЕТ КРАСНОГОРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ